КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 31 июль г.Казань № 637

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының кайбер авыл җирлекләре, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясын, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясын үтәү йөзеннән, шулай ук 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионаты (алга таба – Чемпионат) үткәрү чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 16 августыннан 29 августына кадәр Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан һәм Столбище авыл җирлекләре һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләргә.

2. Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән авыл җирлекләрендә һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә түбәндәгеләрне тыярга:

корыган үлән һәм чүпләр яндыруны, барлык категорияләрдәге җирләрдә учаклар ягуны;

1 – 3 класслы куркынычлыктагы пиротехника әйберләрен Чемпионат үткәргәндә җәлеп ителгән объектлардан 100 метр якынлыкта куллануны.

3. Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында гражданнарга хәбәр итәргә.

4. Бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

халык арасында янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалау эшләрен планлаштыруны һәм үткәрүне, бу юнәлештә массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлекне оештыруны;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче система көчләренең һәм чараларының мөмкин булган янгыннарны сүндерүгә әзерлегенә тикшерүләр үткәрүне;

2019 елның 16 августыннан 29 августына кадәр гражданнар тарафыннан янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлүе буенча урман-парк зоналарына, гражданнарның массакүләм ял итү урыннарына, шулай ук Чемпионат үткәргәндә җәлеп ителгән объектлар янындагы территорияләргә патрульлек итүне оештыруны;

бу карарның 2 нче пункты үтәлешен тикшерүдә тотуны тәэмин итүне;

атна саен башкарылган эш турында Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына мәгълүмат бирүне.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин